| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2022 Бима авылы № 20

«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 24.03.2022 елның 9 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 24.03.2022 елның 9 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитетының карарына өстәп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.Г. Ишпаев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль
районы Бима авыл
җирлеге Башкарма комитетының
24.03.2022 елның 9 номерлы
карары белән расланды
(карар редакциясендә
24.11.2022 № 20 )

**«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 24.03.2022 елның 9 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитетының карарына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының 24.03.2022 елның 9 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гарызнамәче тарафыннан һәр сорауны электрон формасын тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең дөрес тутырылмаган электрон формасындагы бүлекне ачыклаганда мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе турында электрон формада хәбәр ителә.».